Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының
«Иске Гришкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
гражданнары җыены карары

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге составына керүче Иске Гришкино авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2021 елның 21 декабреннән № 2

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлеге составына керүче Иске Гришкино авылында гражданнар җыены карар итте:

1. Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авылы җирлегенең Иске Гришкино авылында теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2020 елда үзара салым акчаларын - 300 сум һәм 1, 2 төркем инвалидлар, 18 яшькә кадәр тәрбиядә булган күп балалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүгә чакырылган гражданнар өчен бер тапкыр түләнә торган түләүне киметергә, әлеге категориядәге гражданнар өчен 150 сум күләмендә түләү кертергә.

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрергә:

- Иске Гришкино авылына су насосын сатып алу;
- Иске Гришкино авылында җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
- Иске Гришкино авылында үзәк суүткәргеч системасына кое урнаштыру өчен җир эшләре (копка);
- Иске Гришкино авылына үзәк суүткәргеч коесы өчен комплектта бокра сатып алу;
- Иске Гришкино авылында зиратта агачлар кисү;
- Иске Гришкино авылында үзәк суүткәргечкә задвижкаларны урнаштыру;
- Иске Гришкино авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;
- Иске Гришкино авылында чүплекне рекультивацияләү;
- Иске Гришкино авылында су агып торучы торбаларны чистарту.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Иске Гришкино авылы, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы В.В.Мамакова